


*Күәм урта гомуми белем мәктәбе газетасы* *№2 Октябрь 2024 ел*



**5 октябрь – хөрмәтле укытучыларыбызның һөнәри бәйрәме. Бәйрәмегездә Сезгә озын, сәламәт гомер, тыныч тормыш һәм эшегездә зурдан - зур уңышлар телибез.**

## Беренче укытучым

Беренче дәрес...Беренче кыңгырау...Беренче укытучы...Бер караганда гади генә тоелган нәрсәләр булса да, кеше күңелендә мәңге истә кала торган кыйммәтләр алар. Сизелер - сизелмәс буяу исе аңкып торган озын, якты коридордан бер кулыңа портфель, икенче кулың белән укытучы апаны җитәкләп беренче дәрескә бару - балачакның иң рәхәт, иң самими, онытылмас мизгеледер, мөгаен.

2015 елның 1 нче сентябрендә мин дә, башка 2008 елгы балалар кебек, тәүге тапкыр мәктәп бусагасын атладым. Күәм урта гомуми белем бирү мәктәбенең беренче сыйныфына без 13 бала булып килеп кердек. Белем иленә илтүче олы юлымда, гаҗәеп ихлас, сабыр, һәр баланы үзенекедәй якын итүче кеше насыйп булды. Сүзем, беренче укытучым Борханова Римма Нурмөхәммәт кызы турында. Якын итеп, мин аңа апа, диеп эндәшәм. Римма апаның һәр дәресе, һәр җөмләсе, һәр сүзе минем нәни йөрәгемдә үз урынын алды. Аның кырык биш минутлык дәресләре - сихри дөнья. Бергәләшеп шул дөньяны ачу, һәр почмагын өйрәнү, эзләнү - табулар безнең өчен үтә кызыклы иде. Үсә төшкәч кенә аңладым, башлангыч сыйныф укытучысының дәресләре төгәл кырык биш минуттан гына тормый икән бит. Ул минутлар тәнәфескә тоташа, ә тәнәфес яңа дәрескә ялгана... Башлангыч сыйныф укытучысы, дәресләр тәмамлангач та өенә ашыга алмый, чөнки аның мең төрле сорауга җавап эзлисе, сыңар аяк киеменең хуҗасын табасы, кемнедер өенә кадәр илтәсе, юатасы-кайгыртасы бар.

2015 елда мәктәпкә кергән нәниләр, быел унынчы тапкыр мәктәпкә килде. Римма апа белән унынчы тапкыр мәктәп юлыннан бергә атлыйбыз. Ул әле дә безнең белән: төпле киңәшләрен бирер, юатыр, мактар, кирәк чакта җиңелчә шелтәләр дә. Алга таба да, гел шулай булачагына ихлас ышанам. Бәйрәм белән сезне, Беренче Укытучым!

**10 сыйныф укучысы Баһавиев Әдел**



## Мой любимый учитель

Когда передо мной встал вопрос, о каком предмете написать, я серьезно задумалась. Хочется рассказать сразу о нескольких, но все же мой выбор пал на предмет, который,как мне кажется, сильно влияет на меня. Говорю я о математике.

Мой любимый предмет ведет прекрасная учительница, замечательная женщина Хакимзянова Нурания Идерисовна. Познакомились мы с ней, когда пришли в шестой класс.

Многие считают математику слишком сложным и скучным предметом,но Нурания Идерисовна всегда умеет оживить скучные уроки.Урок математики интересен тем, что там развиваются умственные способности. Нурания Идерисовна не жалеет собственного времени для того, чтобы помочь нам освоить новый материал, закрепить пройденный.

Пройдут годы, многое изменится. Я стану взрослым, овладею любимой профессией, но обязательно вернусь в родные стены, приду в класс, где мы учились математике, учились у нее, прекрасной учительницы Нурании Идерисовны.

**ученица 9 класса, Зиганшина Замира**

## Укытучы нинди була дисезме?

Безнең Римма апа кебек була. Ул безнең беренче укытучыбыз. Без сыйныфта 9 укучы. Барыбыз да бик шуклар. Апабыз сабыр гына безгә белем бирә. Күп нәрсәләр беләбез инде. Олимпиадаларга әзерләнәбез, ярышларда катнашабыз.

Укытучы бар эшкә дә оста, уңган, акыллы булырга тиеш. Римма апа нәкъ шундый. Ул рәссам да, ул җырчы да. Матур итеп рәсем ясарга , җырларга һәм биергә өйрәтә.

Ул спортсмен да. Чаңгыда оста шуа, велосипедта җилдерә генә. ЮИД түгәрәгендә безгә юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтеп, иминлегебезне саклый. Римма апаны мәктәптә укытучылар да, укучылары да ихтирам итәләр. Яхшы хезмәте өчен ул мактау кәгазьләре белән бүләкләнеп тора.

Римма апабызны яратабыз. Безнең холыкларыбызга түзеп укыткан өчен апабызга зур рәхмәт.

**2 сыйныф укучысы Садриева Ралия**



## Һөнәрләрнең иң асылы

Һөнәрләрнең ниндиләре генә юк. Һәр кеше үзенә якынын сайлый ала. Ә шулай да, һөнәрләрнең иң асылы - укытучы. Укытучы - катлаулы да, мактаулы да, шул ук вакытта кирәкле дә һөнәр иясе. Минем язмам һәр һөнәрнең дә асылы - татар теле һәм әдәбияты, тарих фәне укытучысы, дөресрәге, яраткан укытучым, сыйныф җитәкчем Сөнгатова Гөлнара Зөлкарь кызы турында.

Ул бөтен гомерен яшь буынга белем һәм тәрбия бирүгә багышлаган. Укытучы дигән бөек исемне һәрбер кеше дә йөртә алмый. Минемчә, аның өчен табигать биргән зур илаһи көч, сабырлык, зирәклек һәм акыл тирәнлеге, өмет, ышаныч һәм ныклы иман кирәк. Нәкъ менә шушы матур сыйфатларның барын да үзендә туплаган минем укытучым!

Ә инде 5 нче сыйныфка Күәм урта мәктәбенә укырга килгәч, Гөлнара апа мине үзенең ягымлы тавышы белән белем дөньясына алып кереп китте. Өч ел сизелми дә үтеп китте. Без укытучыбыз белән төрле бәйрәмнәр үткәрдек, конкурсларда катнашып җиңүләр яуладык, табигать кочагына экскурсияләргә йөрдек. Укытучыбыз безне хезмәтне сөяргә, табигатьне яратырга, олыларны хөрмәт итәргә, кешелекле булырга да өйрәтә. Ул безнең һәрберебезне аңлый белә, тыңлый белә. Миңа аның янында җылы, рәхәт, күңелле.

Безгә тарих фәнен дә укыта ул. Шундый җиңел итеп аңлата, төшендерә белә. Татар теле һәм әдәбияты фәне буенча да безгә тирән белемнәр бирә.

Без аны бик яратабыз, хөрмәт итәбез. Ул гел безнең янда булсын иде дип телибез.

**7 нче сыйныф укучысы, Шакирова Камилә**

## Укытучым

Дөньяда һөнәрләр бик күп. Минемчә, һәр кеше һөнәрнең үзенә ошаганын сайларга тиеш. Үзен сайлаган һөнәрнең чын остасы булу өчен бик күп укырга, белемле булырга кешене укытучы өйрәтә.

Мин үземнең укытучым Ганиева Люция апа турында сөйләп китәсем килә. Ул бик әйбәт укытучы. Гадел һәм түземле, тыныч һәм ягымлы. Без аны бик хөрмәт итәбез. Ул бездән чын шәхес тәрбияләргә бөтен көчен бирә.

Укытучыдан башка кеше бер һөнәргә дә өйрәнә алмас иде. Укытучы - барлык һөнәрләргә дә юл ачучы ул.

**3 нче сыйныф укучысы, Халитова Иркә**





## Мой любимый учитель.

Я учусь в МБОУ «Кубянская СОШ», у нас много учителей. В 6 классе нам добавили урок обществознание. И я начала любить как сам урок, так и самого учителя. Учительницу зовут Халикова Гульфия Зуфаровна. Учитель – это благородная и ответственная профессия. Не каждый человек сможет поладить с детьми и интересно объяснить материал. Благодаря учителю ученик может раскрыть свой потенциал, научиться чему-то новому. От учителя мы получаем не только знания по предмету, но и жизненный опыт.

Наверное, у каждого из нас есть любимый учитель. Так почему же мне так понравились её уроки? Возможно, для многих урок обществознания это скучные неинтересные материалы. Но Гульфия Зуфаровна умеет преподнести материал так, чтобы было всем интересно и понятно, на уроке мы можем задавать вопросы, потому что знаем, что обязательно получим ответы.

Однажды мы изучили тему «Наши права и обязанности». Я узнала, что такое право и обязанность, свои права. Гульфия Зуфаровна не только учитель, она еще и наша классная руководительница. Мне тоже понравилась сама она, потому что я считаю, что она понимающая. Мне нравится её личность и её отношение к нам, она учит нас решать наши собственные проблемы, а не делать это за нас.

Ещё на уроке мы смотрим классные и интересные презентации по теме. На её уроке я всегда получаю «5», так как мне очень нравится делать домашние задания по рабочей тетради.

Гульфия Зуфаровна справедливая и доброжелательная. Мы в ответ тоже стараемся радовать её хорошими оценками за изученный материал. По каждому поводу она даёт правильный совет. Гульфия Зуфаровна организовывает в нашей школе мероприятия, конкурсы. Она искренне любит свой предмет и стремится поделиться своими знаниями, интересно преподнося урок.

Я думаю, что не каждый человек может стать учителем, эта профессия требует огромного терпения, труда, интереса к своему предмету. Учитель не только обучает детей, но и воспитывает в них личность.

Вот через несколько лет учеба в школе закончится и передо мной откроется дорога во взрослую жизнь. Нам будет очень жаль расставаться с Гульфией Зуфаровной. Я считаю, что все предметы, изученные в школе так или иначе остаются в памяти учащихся.

**ученица 6 класса, Мирхазианова Алия**